КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 апрель г.Казань № 395

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларының Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гражданнарга мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына керми торган ашыгыч медицина ярдәме, беренчел медицина-санитария ярдәме (гражданнарга төп авыруы (хәле) буенча диспансер күзәтүен кертеп) күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус социаль түләүләрне гамәлгә ашыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларының Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гражданнарга мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына керми торган ашыгыч медицина ярдәме, беренчел медицина-санитария ярдәме (гражданнарга төп авыруы (хәле) буенча диспансер күзәтүен кертеп) күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә (медицина оешмалары җитәкчеләреннән һәм аларның урынбасарларыннан, шулай ук берьюлы ике вазифада эшләү һәм төп урыннан башка икенче урында эшләү очракларыннан тыш) (алга таба – шул ук эзлеклелектә медицина оешмалары, медицина хезмәткәрләре) махсус социаль түләүләр (алга таба – шул ук эзлеклелектә акча, түләү) билгеләргә.

2. Медицина хезмәткәрләренең түбәндәге категорияләренә ай саен бирелә торган түләүне, бер медицина хезмәткәре исәбеннән чыгып, түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

а) территориаль участок принцибы буенча беркетелгән халыкка беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче, шулай ук гражданнарга төп авыруы (хәле) буенча диспансер күзәтүен гамәлгә ашыручы медицина оешмаларында эшләүче, авыруына (хәленә) бәйле рәвештә һәм профилактика максаты (тикшерүләр үткәрүне кертеп) белән гражданнар мөрәҗәгать итүче (булучы) табибларга – 14 500,0 сум;

б) ашыгыч медицина ярдәме станцияләре (бүлекләре) табибларына – 11 500,0 сум;

в) бу пунктның «а» пунктчасында күрсәтелгән табиблар белән эшләүче, шулай ук территориаль участок принцибы буенча беркетелгән халыкка авыруына (хәленә) бәйле рәвештә яки профилактика максаты (тикшерүләр үткәрүне кертеп) белән беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче һәм (яки) гражданнарга төп авыруы (хәле) буенча диспансер күзәтүен гамәлгә ашыручы урта медицина белемле белгечләргә – 6 500,0 сум;

г) ашыгыч медицина ярдәме станцияләренең (бүлекләренең) фельдшерларына һәм шәфкать туташларына – 7 000,0 сум;

д) территориаль участок принцибы буенча гражданнарга беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларының кече медицина персоналына – 4 500,0 сум;

е) ашыгыч медицина ярдәме станцияләренең (бүлекләренең) кече медицина персоналына – 4 500,0 сум.

3. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

календарь ай өчен түләү медицина хезмәткәренең хезмәт шартнамәсендә билгеләнгән хезмәт функциясен үтәвеннән, шулай ук тиешле календарь айда эш көннәре өчен эш вакытын исәпкә алу табеле буенча суммар эшләнгән вакыттан чыгып исәпләнә. Эшләнгән вакытның исәп-хисабы санның унынчы өлешенә кадәр зур якка түгәрәкләп алып барыла;

календарь ай өчен медицина хезмәткәренә түләү күләмен билгеләгәндә, календарь айда медицина хезмәткәре тарафыннан фактта эшләнгән эш сәгатьләре саны белән медицина хезмәткәренә Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән эш атнасы дәвамлылыгыннан чыгып исәпләнгән тиешле айга эш вакыты нормасы буенча эш сәгатьләре санының нисбәте Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Били торган вазыйфасына һәм (яки) белгечлегенә карап, медицина хезмәткәрләренең эш вакыты дәвамлылыгы турында» 2003 елның 14 февралендәге 101 номерлы карарында билгеләнгән тәртиптә исәпләп чыгарыла. Әгәр нисбәте тигез яки бердән күбрәк булса, түләү максималь күләмдә гамәлгә ашырыла. Әгәр нисбәте бердән азрак булса, түләү күләме алынган күрсәткечкә пропорциональ рәвештә билгеләнә;

түләү медицина хезмәткәрләренә Россия Федерациясе Хезмәт кодексында билгеләнгән гарантияләрне бирү максаты белән уртача хезмәт хакын исәпләгәндә исәпкә алына.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгын бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыруга каралган акча белән баш эш итүче итеп билгеләргә.

5. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин